
# *Минем нәсел шәҗәрәм*



***Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әхмәтгалиева Эльмира Алис кызы***

•

# Эшнең төп соравы

**Үткән буыннарда, нәселдә нинди шәхесләр бар?**

# Эшнеӊ максатлары


1.Гаилә архивындагы кыйммәтле документларны, фотосүрәтләрне, хатларны, иске кулъязмаларны өйрәнү.

2.Нәсел агачын – шәҗәрәмне төзү.

3.Нәселебезгә караган шәхесләр турында материал туплау.

4.Барлык туганнарны әлеге изге эшкә тарту.

5.Доклад һәм презентация әзерләү.



Шәҗәрә - нәсел агачы, бабаларыңның әллә ничә буынга кадәр исемнәрен, дөньядан үтү тәртипләрен белү дигән сүз.

Шәҗәрә төрләре

*Күтәрелә баручы шәҗәрә* – бу шәҗәрәдә аерым бер кешедән башлыйлар, аннан соң буыннар буенча атасына, бабасына, бабасының атасына һ.б., билгеледән билгесезлеккә баралар.

*Төшә баручы шәҗәрә* - бу шәҗәрәне иң ерак ата-бабадан башлыйлар һәм аннан соңгы яшерәк буыннарга күчәләр.

*Ирләр шәҗәрәсе* – анда ирләрдән килеп чыккан буыннарны гына күрсәтәләр, хатыннары янәшә язып куела.

*Катнаш шәҗәрә* – анда ир-ат һәм хатын кыз рәте буенча барлык ата-бабаны күрсәтәләр.

*Туганлык шәҗәрәсе* – булган якын туганнар языла.

# Эш буенча нәтиҗәләр

1.Мин үземнең гаилә шәҗәрәсен төзегәндә шуны аңладым: әби-бабаларны өйрәнгәндә кеше туган иленең, туган төбәгенең, туган йортының, үз халкының чыгышын белә, татар милләте тарихы белән якыннан таныша.

2.Мин үземнең гаиләмнең шәҗәрәсен төзедем.

3.Нәселебездә булган күренекле шәхесләр – туганнар турында тулырак мәгълүмәт алдым.

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!